# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Татарстан Республикасы Президентының намусын һәм абруен яклау турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

**1 статья.** "Татарстан Республикасы Президентының намусын һәм абруен яклау турында" Татарстан Республикасының 1991 елның 4 июлендәге Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992 ел, N 2) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Президентының намусын һәм абруен яклау турында

Татарстан Республикасы
З А К О Н Ы

1 статья. Татарстан Республикасы Президентын халык алдында хурлау яисә аңа карата яла ягу, әгәр әлеге гамәлләр җинаять җаваплылыгына китермәсә, -

егерме минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салуга китерә.

Шул ук гамәлләр кабат, шулай ук матбугат продукциясен (китаплар, брошюралар, листовкалар һәм басма яки үзгә ысул белән ишәйтелгән башка продукция) яисә массакүләм мәгълүмат чараларын кулланып башкарылса, -

матбугат продукциясен конфискацияләп, утыз биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салуга китерә.

2 статья. Массакүләм мәгълүмат чарасы тарафыннан Татарстан Республикасы Президентын хурлый торган яисә аңа карата яла яга торган хәбәрләр тарату, -

вакытлы матбугат басмасы·продукциясен (тиражны яки тиражның бер өлешен) конфискациялəп, йөз илле минималь хезмəт хакы күлəменə кадəр штраф салуга китерə.

3 статья. Əлеге Закон күздə тоткан административ хокук бозулар турындагы эшлəр, административ хокук бозулар турында законнар билгелəгəн тəртиптə район (шəһəр) судлары тарафыннан карала".

**2 статья.** Əлеге Законны басылып чыккан көненнəн гамəлгə кертергə.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шəймиев

Казан шəһəре,
1996 елның 13 июне
N643

4/namuc.txt